ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«08» июнь 2022 ел № 142

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының 2021 елның 25 мартындагы
80 номерлы карары белән расланган “2021-2022 елларга
Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында
физик культура һәм спортны үстерү"
муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Гамәлдәге законнарга хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча муниципаль норматив хокукый актны тәңгәлләштерүгә бәйле рәвештә, шулай ук Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты арасындагы «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә физик культураны, массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү турында» Килешү нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 25 мартындагы 80 номерлы карары белән расланган “2021-2022 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү" муниципаль программасына (алга таба –Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Программаның паспортында «Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="4">Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары:</td><td colspan="3">Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан программаны финанслауның гомуми күләме:</td></tr>
<tr><td>ел</td><td>җирле бюджет</td><td>республика бюджеты</td></tr>
<tr><td>2022 ел</td><td>28,7 мең сум</td><td>2 872,4 мең сум</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>28,7 мең сум</td><td>2 872,4 мең сум</td></tr>
</table>

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**